**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.10.2020 г.Казань № 287

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча эшне камилләштерү максатында б о е р а м:

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә (Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 11 ноябреннән 356 номерлы, 2020 елның 17 июленнән 216 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) кул куелган 307 номерлы «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2020 елның 9 октябреннән
287 нче номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының 2019 елның 7 октябрендә кул куелган 307 номерлы «Спорт мастерлыгына кандидат» һәм «беренче спорт разряды» спорт разрядларын, спорт хөкемдарларының «беренче категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу һәм Россия Федерациясе Спорт министрлыгына спорт исемнәрен, «бөтенроссия категорияле спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, торгызу өчен тәкъдимнәр юллау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.8 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә тәкъдим итәргә:

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Спорт исемен бирү өчен:

а) гомумроссия спорт федерациясенең спорт исеме бирү өчен тәкъдимне килештерүдән нигезләмәле баш тарту;

б) спортчының спорт исеме бирү өчен кирәкле документларда күрсәтелгән нәтиҗәләренең Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган нормалар, таләпләр һәм аларны башкару шартларына туры килмәве;

в) спортчының спорт дисквалификациясе;

г) ярышлар һәм (яки) физкультура чараларының оештыручылары тарафыннан расланган нигезләмәләр (регламентлар) белән билгеләнгән ярышлар һәм (яки) физкультура чараларына кертү шартларын бозу;

д) спортчы норманы, аларны үтәү таләпләрен һәм шартларын үтәгән ярышлар кысаларында уздырылган допинг-тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән спортчының допингка каршы кагыйдәләрне бозуы хакында тиешле допингка каршы оешма карары булу.

2.2. Спорт разрядын бирү өчен:

а) спортчының спорт разряды бирү өчен кирәкле документларда күрсәтелгән нәтиҗәләренең Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган нормалар, таләпләр һәм аларны башкару шартларына туры килмәве

б) спортчының спорт дисквалификациясе;

в) ярышлар һәм (яки) физкультура чараларының оештыручылары тарафыннан расланган нигезләмәләр (регламентлар) белән билгеләнгән ярышлар һәм (яки) физкультура чараларына кертү шартларын бозу;

г) спортчы норма, таләпләрен һәм үтәү шартларын башкарган ярышлар кысаларында үткәрелгән допинг-тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән спортчының допингка каршы кагыйдәләрне бозуы хакында тиешле допингка каршы оешма карары булу .

2.3. Спорт разрядын раслау өчен:

а) спортчының Үтенеч язуында күрсәтелгән нәтиҗәләренең Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган нормалар, таләпләр һәм аларны үтәү шартларына туры килмәү;

б) спортчы спорт разрядын раслаган ярышка кадәр яки ярышлар үткрәү көнендә килеп чыккан спорт дисквалификациясе;

в) ярышлар һәм (яки) физкультура чараларының оештыручылары тарафыннан раслана торган нигезләмәләр (регламентлар) белән билгеләнгән ярышлар һәм (яки) физкультура чараларына кертү шартларын бозу.

2.4. Спорт исеменнән мәхрүм итү өчен түбәндәгеләр булып тора:

а) бирелгән белешмәләрнең Нигезләмәнең 64 пунктында каралган спорт исеменнән мәхрүм итү өчен нигез булып торган мәгълүматларга туры килмәве;

б) моңа кадәр шул ук нигезләмәләр буенча бирелгән спорт исеменнән мәхрүм итү турында гариза буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгының карары булу.

2.5. Спорт разрядыннан мәхрүм итү өчен сәбәп булып түбәндәгеләр тора:

а) бирелгән мәгълүматларның ББСК нигезләмәсенең 83 пунктында каралган спорт разрядыннан мәхрүм итү өчен нигезләмәләргә туры килмәве;

б) спорт федерациясе, физкультура-спорт оешмасы, спорт әзерлеген тормышка ашыра торган оешма, белем бирү оешмасы яисә Гариза бирүче тарафыннан шул ук нигезләмәләр буенча моңа кадәр спорт разрядыннан мәхрүм итү турында гариза буенча карар булу.

2.6. Спорт исемен кире торгызу өчен:

а) бирелгән мәгълүматларның ББСК Нигезләмәсендәге 73 пунктның икенче абзацында каралган спорт исемен торгызу өчен нигезләмәгә туры килмәве;

б) моңа кадәр шул ук сәбәпләр буенча бирелгән спорт исемен торгызу турында гариза буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгының карары булу сәбәп булып тора.

2.7. Спорт разрядын кире торгызу өчен:

а) бирелгән мәгълүматларның ББСК Нигезләмәсендәге 92 пунктның икенче абзацында каралган спорт разрядын торгызу өчен сәбәпкә туры килмәве;

б) спорт федерациясе, физкультура-спорт оешмасы, спорт әзерлеген тормышка ашыра торган оешма, белем бирү оешмасы яисә Гариза бирүче тарафыннан шул ук нигезләмәләр буенча моңа кадәр спорт разрядын кире торгызу турында гариза буенча карар булу сәбәп булып тора.

2.8 Хөкемдар квалификация категориясен бирүдә Россия Федерациясе Спорт министрлыгы тарафыннан расланган Квалификация таләпләрен үтәмәү (спорт төрләре буенча) нигез булып тора.

2.9. «Бөтенроссия категорияле хөкемдар» мәхрүм итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) бирелгән мәгълүматларның Спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмәнең 48 пунктында каралган бөтенроссия категориясеннән мәхрүм итү өчен нигезләмәгә туры килмәве;

б) моңа кадәр шул ук нигезләмәләр буенча бирелгән бөтенроссия категориясеннән мәхрүм итү турында гариза буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгының карары булу.

2.10. «Беренче квалификация категорияле хөкемдар» мәхрүм итү өчен:

а) бирелгән мәгълүматларның Спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмәсенең 67 пункты тарафыннан каралган квалификация категориясеннән мәхрүм итү өчен нигезләмәгә туры килмәве нигез була.

2.11. «Бөтенроссия категорияле хөкемдар» торгызу өчен:

а) бирелгән мәгълүматларның Спорт хөкемдарлары турындагы нигезләмәнең 57 пункты тарафыннан каралган бөтенроссия категориясен торгызу өчен нигезләмәгә туры килмәве;

б) моңа кадәр шул ук нигезләмәләр буенча бирелгән бөтенроссия категориясен торгызу турында гариза буенча Россия Федерациясе Спорт министрлыгының карары булу.

2.12. «Беренче квалификация категорияле хөкемдар» квалификация категориясен торгызу өчен түбәндәгеләр сәбәп була:

а) тапшырылган белешмәләрнең спорт хөкемдарлары турындагы Нигезләмәнең 76 пунктында каралган квалификация категориясен торгызу өчен нигезгә туры килмәве;

б) квалификация категориясен торгызу турында региональ спорт федерациясе яисә спорт хөкемдары тарафыннан элегрәк бирелгән гариза буенча оешманың карары булу;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматлары гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Инвалидларның (кресло-коляскалар һәм озатып йөрүче этләрне дә кертеп) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуын оештыру максатларында түбәндәгеләр тәэмин ителә:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү шартлары;

мөстәкыйль рәвештә яки  хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә Министрлык территориясе буйлап хәрәкәт итү, Министрлык бинасы һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге;

транспорт чарасына утырту һәм бинага керү алдыннан аннан төшерү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәме белән;

күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт функцияләре нык бозылган инвалидларны озата бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне, аларның тормыш эшчәнлегенең чикләүләрен искә алып, тиешле итеп урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайльнең рельеф-ноктал шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт бирү;

махсус укытуны раслаучы документ булганда, озатып йөрүче этне бинага кертү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтү алуга һәм объектлардан файдалануга комачаулаучы каршылыкларны җиңеп чыгуда башка кирәкле ярдәм күрсәтү;

инвалидлар организмының функцияләре нык бозылуларын һәм тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, аларның физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүе өчен бинаны махсус спорт инвентаре һәм җиһазлар белән тәэмин итү;

инвалидларга, аларда булган тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, махсуслаштырылган төркемнәрдә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру;

инвалидлар белән физкультура һәм спорт дәресләрен үткәрү өчен әзерләнгән хезмәткәрләр булу.

Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның үтемлелеген тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, реконструкция, модернизация узган объектларга карата кулланыла»;

«Хезмәт күрсәтүне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1995 елның 24 ноябреннән «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2015 елның 24 августыннан «Физкультура һәм спорт өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итү, шулай ук инвалидларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» 825 номерлы боерыгы;

2.15 пунктының «Хезмәт күрсәтү яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт » графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябреннән 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 2.4 пункты»;

3 бүлегендәге 3.4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече:

әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавына документларны карый, ягъни спорт разрядын, спорт судьясының квалификация категориясен бирү, мәхрүм итү, квалификация категориясен яңадан торгызу мөмкинлеген яисә разряд, квалификация категориясен бирүдән, мәхрүм итү, яңадан торгызудан баш тарту мөмкинлеген карый һәм бирү турында боерык проектын яисә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, гариза бирүчегә хат әзерли (алга таба – боерык, хат проектлары);

Россия Федерациясе Спорт министрлыгына тәкъдим итүгә бергә җибәрелә торган хат проектын (алга таба – бергә җибәрелә торган хат проекты) яки гариза бирүчегә спорт исемен бирү, мәхрүм итү, спорт исемен бирү һәм «Бөтенроссия категориясендәге спорт хөкемдары» квалификация категориясен бирү өчен тәкъдим итү җибәрүдән баш тарту турында, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хат проекты әзерли.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Бүлек белгеченә гариза җибәргәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрелгән боерык проекты, баш тарту турында хат, озату хаты проекты».